СОВЕТ ЯМБУЛАТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Центральная, д.5, с.
Ямбулатово,
422587

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯМБУЛАТАВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Узәк ур., 5 нче йорт, Ямбулат авылы,
422587

Тел.: (84379) 36-5-18 факс: (84379) 36-5-18

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

25.10.2023 с.Ямбулатово 37 – 196

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 04.08.2023 ел N 416-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы 18.12.2020 ел №4-26 Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 39 статьясындагы 1 пунктында «һәм аларның структур элементларын» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. Нигезләмәнең 40 статьясындагы 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль программаларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләме авыл җирлегенең Башкарма комитеты билгеләгән муниципаль программалар исемлеге һәм структурасы нигезендә бюджет чыгымнарының һәр максатчан статьясы буенча бюджет турындагы карар белән раслана».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Ямбулат авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет-финанс һәм икътисадый мәсьәләләр буенча Ямбулат авыл җирлегенең даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе урынбасары,
Югары Ослан муниципаль районының
Ямбулат авыл җирлеге башлыгы урынбасары М.Н.Ахметзянов